Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль район Советы
КАРАРЫ

2023 елның 20 марты № 137

**2023 елда Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районында муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы, «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексы, Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы муниципаль берәмлеге Советы Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Советы КАРАР ЧЫГАРДЫ:

1. 2023 елда яллаучы (эш бирүче) вәкиле карары буенча Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының җирле үзидарә органнарында һәм муниципаль органнарында муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүгә конкурс үткәрелмәскә мөмкин дип билгеләргә.
2. Әлеге карарның 1 пункты Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесе вазыйфасына билгеләнгәндә кулланылмый.
3. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында дәүләт теркәвенә алганнан соң (pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә (kamskoye-ustye.tatarstan.ru) урнаштырырга.
4. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.
5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Кама Тамагы муниципаль районы башлыгы урынбасары И.Т.Гыйниятовка йөкләргә.

Кама Тамагы муниципаль районы Башлыгы,
Кама Тамагы муниципаль районын Советы рәисе Н. А. Вазыйхов